**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30.04.2025 № 471

Нурлат муниципаль районында «Үзәкләштерелгән бухгалтерияләр, муниципаль берәмлекләр башкарма комитетларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) җитәкчеләре һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 91 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Нурлат муниципаль районында муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренең һәм белгечләренең, баш бухгалтерларының һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 03.04.2025 № 03-12/2212 хаты нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 31 гыйнварындагы 91 номерлы карары (Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 12024 елның 16 августындагы 949 номерлы, 2024 елның 07 ноябрендәге 1346 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләренең һәм белгечләренең, баш бухгалтерларның һәм бухгалтерларының (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) хезмәткә түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль берәмлекләр башкарма комитетлары җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) Нурлат муниципаль районындагы үзәкләштерелгән бухгалтерияләр, баш бухгалтерлар һәм бухгалтерлар) түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә::

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифасы | Вазыйфаи оклад, сум | |
|---|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен | Башкарма комитетның (җирле үзидарәнең башка органының) структур бүлекчәсе (бүлеге) булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |

| | | |
|---|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 37 000 | |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 34 600 | |
| Башкарма комитетның структур бүлекчәсе җитәкчесе (баш бухгалтер) | | 34 600 |
| Бүлек җитәкчесе | 30 500 | 30 500 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 27 800 | 27 800 |
| Бухгалтер | 26 400 | 26 400 |

2. «Нурлат муниципаль районы муниципаль учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе директоры һәм муниципаль берәмлекләрнең башкарма комитетлары җитәкчеләренә штат расписаниеләренә үзгәрешләр кертергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 маеннан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин